Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

2025 елның 05 декабре №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә җыен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле авылында яшәүчеләрне хәл иттеләр:

1.2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;
- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Гарифуллин